# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 4** **10.12.2019 ел**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Октябрь авыл җирлеге составына керүче Бәкәбез торак пунктына 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге Бәкәбез торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Бәкәбез торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә. Бөек Ватан сугышы инвалидлары һәм анда катнашучылар, 1 һәм 2 төркем инвалидлар, Әфганстандагы хәрби хәрәкәтләрдә һәм башка локаль конфликтларда катнашучылар, шулай ук көндезге формада укучы студентлар өчен 500 (биш йөз ) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

1.Бәкәбез авылы янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

2. Бәкәбез авыл халкының ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

3.Рәсми мәдәни-массакүләм чараларны оештыру;

4. Бәкәбез авылы җирлеген төзекләндерүне оештыру;

5. Бәкәбез авылында ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;

6.Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, Бәкәбез авылы суларын чыгаруны оештыру;

7. Бәкәбез авылы җирлегенең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге;

8. Бәкәбез авылы халкының күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру

9. Бәкәбез авылының территориаль планлаштыру документларын әзерләү һәм раслату;

10. Бәкәбез авылы территориясендә яшәүче күзәтүчесез хайваннарны тоту чараларын оештыру”.

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда , Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы, Бәкәбез авылы, Елга урамында урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Октябрь авыл җирлеге башлыгы И.М.Ханнанов